

2026 елда кvренекле татар шагыйре, язучы, тәржемәче, публицист Габдулла Тукайнын тууына 140 ел (1886-1913) тула. Анын татар шигърияте vсешенә керткән олешен бәяләп бетереп булмый. Үзенен тулы булмаган 27 ел эчендә ул йоздән артык шигырь язган. Без, Мордовия татарлары, Габдулла Тукай ижатын горурланып ойрәнәбез – Тукайлы халык без. Анын исеме мәнге безнен кvнелләрдә һәм балаларыбызга да Тукайны ойрәтәбез. Габдулла Тукай (Габдулла Мохәм-мәтгариф улы Тукаев) 1886 елнын 26 апрелендә хәзерге Татарстан Республикасынын Арча районы Кушлавыч авылында доньяга килә. Кеч-кенәдән ятим калган Габдулла, кулдан-кулга йореп, балачагын Сасна, Очиле, Кырлай авылларында уздыра.      Башлангыч белемне Кырлай авылы мәдрәсәсендә ала. 1895 елда булачак шагыйрь хәзерге Уральск шәһәрен-дә яшәvче туганнары гаиләсендә тәрбияләнә. Биредә ул «Мотыйгия» мәдрәсәсендә укый. Татар халык ижатын һәм язма әдәбиятын жентекләп ойрәнә. Гарәп, фарсы, торек, рус һәм башка халыкларнын әдәбиятлары белән таныша. Рус теле аркылы Конбатыш классик әдәбияты казанышларын vзләштерә. Үзе дә беренче шигырьләрен ижат итә. Типографиядә, газета-журнал редакцияләрендә эшли. Жаектагы әдәби-мәдәни хәрәкәт Тукай тормышында хәлиткеч роль уйный. 1905 елгы революция дулкыны белән әдәбиятка килеп кергән әдип монда жәмәгать эшлеклесе, журналист, тәржемәче һәм шагыйрь буларак формалаша. 1907 елнын козендә Тукай Казанга кайта. «Яшен», «Ялт-йолт» журналларын чыгаруда катнаша. Иван Крылов мәсәлләрен, Байрон, Гете, Гейне, Шиллер, Александр Пушкин, Михаил Лермонтов шигырьләрен иректе тәржемә итә. Ул шулай ук татар балалар әдәбиятына нигез салучыларнын берсе дә.
Мордовия татарлары мәктәптән ук туган телгә, туган жиргә мәдхия укыган «Шvрәле» (1907), «Пар ат» (1907), «Туган тел» (1909), «Китмибез!» (1907), «Сорыкортларга» (1906), «Печән базары, яхуд Яна Кисекбаш» (1908) һәм башка әсәрләре, публицистикасы белән танышлар. Ө бишек жыры белән Тукай кvнелебезгә сенгән. Без анын ижатын ойрәнәбез,

анын белән горурланабыз, киләчәк буынга да тапшырырга тырышабыз.
Тукайнын тормышы, ижаты турындагы әдәбиятны 1907 елдан башлап бу конгә кадәр чыккан матбугатта бик кvп очратырга момкин: аерым китап-жыентыкларда, газета-журнал бит-ләрендә менләп мәкалә һәм истә-лекләр басыла. Татар телендә генә дә Тукайга багышланган берничә йоз шигырь, поэма, роман һәм пьеса языла.
Габдулла Тукай 1913 елнын 15 апрелендә Казанда vпкә авыруыннан вафат була, Яна бистә зиратында жирләнә. Быел 15-17 апрельдә vткән Ботендонья «Туган тел» форумында катнашкан Мордовия делегатлары да  Тукай һәйкәленә чәчәкләр салуда катнаштылар.